КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 7 октябрь г.Казань № 912

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Әфганстан Республикасында хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Төньяк Кавказ регионы территориясендә кораллы конфликтларда һәм контртеррорчылык операцияләрдә катнашучылар мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Координация советын төзү турында» 2020 ел, 10 август, 674 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Әфганстан Республикасында хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Төньяк Кавказ регионы территориясендә кораллы конфликтларда һәм контртеррорчылык операцияләрдә катнашучылар мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Координация советын төзү турында» 2020 ел, 10 август, 674 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Әфганстан Республикасында хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Төньяк Кавказ регионы территориясендә кораллы конфликтларда һәм контртеррорчылык операцияләрдә катнашучылар мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Координация советы составына кертергә:

| | |
|---|---|
| Лоханов Павел Николаевичны | Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге идарәчесен (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Мостаев Рим Шаһгали улын | «Россия офицерлары» оборона сәләтен һәм хокук тәртибен ныгытуга ярдәм итү Бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлеге Президиумы әгъзасын (килешү буенча) |
| Низамов Ригель Хәләф улын | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Баш медик-социаль экспертиза бюросы» федераль казна учреждениесенең медик-социаль экспертиза буенча баш экспертын - җитәкчесен (килешү буенча) |
| Стогниев Иван Даниловичны | «Сугышчан туганлык» бөтенроссия ветераннар иҗтимагый оешмасының Татарстан республика бүлекчәсе җитәкчесен (килешү буенча) |
| Тишаев Гафурҗан Кадыйр улын | Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Ветераннар советы әгъзасын (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин